**Республика Татарстан**
**САКЛОВ-БАШСКИЙ МУНИЦИ-ПАЛЬНЫЙ РАЙОН СОВЕТ САКЛОВ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
ул. Ленина, д. 93 а,
с. Саклов-Баш, 423373.
Телефон: (85559) 4-33-38
E-mail: Sakb.Sar@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САКЛАУБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Ленин урамы, 93 а йорт,
Саклаубаш авылы, 423373.
Телефон: (85559) 4-33-38
E-mail: Sakb.Sar@tatar.ru

ИНН/КПП 1636005510/164701001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.11.2019 г. № 108

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021,2022 нче еллар план чорына бюджеты турында карар проекты кабул итү турында

“Россия Федерациясенлә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы “Саклаубаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы “Саклаубаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль райны Саклаубаш авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 елларның план чорына бюджеты турында” карар проектын беренче укылышта кушымта нигезендә кабул итәргә.
2. Әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшне дәвам итәргә.
3. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021, 2020 нче елларга план чорына бюджеты турында” карар проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем оештырырга:
   1 Габидуллина Л.М. –төркем җтәкчесе
   2 Шайдуллин Р.Г. - төркем әгъзасы
   3 Сабирзянов Р.Г.- төркем әгъзасы
   4 Мухаметшина Г.Я. - төркем әгъзасы
   5 Фатихов З.Х. .- төркем әгъзасы
4. Карар проектына гражданнарның тәкъдимнәре: Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Саклаубаш авылы, Мулланур Вахитов урамы, 36в йорт адресына язмача җибәрелә дип билгеләргә.

5. Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең 2020 нче елга һәи 2021, 2022 нче елларның план чорына бюджеты турындагы карар проекты буенча ачык тыңлауларны 2019 елның 6 нчы декабрендә 14.00 сәгатькә билгеләргә.

6 Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Советы депутатларының төзәтмәләрен һәм карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, карар проектын эшләп бетерергә, аны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Советы каравына 2019 елның 12 декабренә кадэр кертергә.

7 Әлеге карарны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” (PRAVO TATARSTAN. RU) һәм Татарстан Республикасы “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

8 Әлеге карарны контрольдә тотам.

Саклаубаш авыл
җирлеге Советы рәисе: Л.М.Габидуллина



Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Советының 2019 нчы елның
25 ноябрендә кабул ителгән
138 нче номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021,2022 нче еллар план чорына бюджеты турында карар

Статья 1

1.Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең 2020 нче елга бюджетының төп характеристикасын расларга:

1) Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге бюджетының фаразланган гомуми керем күләме 3 807,1 мең сум күләмендә;
2) Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге бюджетының гомуми чыгымнары күләме 3807,1 мең сум;
3) Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге бюджеты кытлыгы
 0,0 мең сум.

2.Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең 2021 нче елга һәм 2022 нче елга бюджетының төп характеристиксын расларга:

1) Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең 2021 нче елга фаразланган кеременең гомуми күләме 3932,9 мең сум һәм 2022 нче елга 4067,6 мең сум күләмендә;
2) 2021 нче елга гомуми чыгымнары күләме 3932,9 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 100,0 мең сум күләменлә, һәм 2022 нче елга 4067,9 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвешә расланган чыгымнар 205,0 мең сум күләмендә.
3) Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге бюджеты кытлыгы
 2021 елга 0,0 мең сум һәм 2022 нче елга 0,0 мең сум.

3.Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче еллар план чорына бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

Статья 2

1.Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге 2021 нче елның 1 гыйнварына эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча буычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

2.Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге 2022 нче елның 1 гыйнварына эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә

расларга, шул исәптән Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча бурычының югары чиген 0,0 мең сум кләмендә расларга.
3.Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге 2023 нче елның 1 гыйнварына эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча буычының югары чиген 0,0 мең сум кхләмендә расларга.
4.Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең 2020 нче елга муниципаль бурычының чик күләмен 0,0 мең сум, 2021 нче елга 0,0 мең сум, 2022 нче елга 0,0 мең сум күләмендә билгеләргә.

Статья 3
Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге бюджетында 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче еллар план чорына фаразланган керем күләмен исәпкә алырга.

Статья 4
Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 60,1 статьясындагы 2 нче пункты нигезендә Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге бюджетының 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче еллар план чорына керемнәрен бүлү нормативларын расларга, әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә карар кабул ителде.

Статья 5
1. Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген шушы карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга.
2. Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген шушы карарның 5 нче кушымтасы нигезендә расларга.

Статья 6
1.Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге бюджетының 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче еллар план чорына чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарның 6 нчы кушымтасы нигезендә расларга.
2. Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге бюджетының бүлекләр, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге муниципаль программалары һәи эшчәнлекнең программасыз юнәлешләре), 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне раслау турныда” 2007 ел, 7 нче кушымта нигезендә.
3. Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялар (Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге муниципаль программалары һәи эшчәнлекнең

программасыз юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге карарның 8 нче кушымтасы нигезендә расларга.
4. Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге бюджетының 2020 нче елга
халык алдында норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2021 нче елга 0,0 мең сум, 2022 нче елга 0,0 мең сум күләмендә расларга.

Статья 7
1.Саклаубаш авыл җирлеге бюджетының 2020 нче елга, төзелгән килешүләр нигезендә, мәдәният хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү буенча шартлар тудыру буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен 2020 нче елга 1 964,0 мең сум, 2021 нче елга 2139,1 мең сум, 2022 нче елга 2117,2 мең сум күләмендә башка бюджетара трансфертлар күләмен раслау.
2.2020 нче елда Саклаубаш авыл җирлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны күчерү ай саен тигез өлешләр белән башкарыла дип билгеләргә.

Статья 8
Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге бюджетында Сарман муниципаль районы бюджетыннан алына торган акчаны исәпкә алырга:
1)2020 нче елга бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр – 2852, 0 мең сум, 2021 нче елга – 2966,6 мең сум, 2022 нче елга – 3090,1 мең сум;
2) 2020 нче елга хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру өчен авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр – 92,1 мең сум, 2021 нче елга – 92,2 мең сум, 2022 нче елга- 93,7 мең сум

Статья 9
1.Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары 2020 нче елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук муниципаль учреждение хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

Статья 10
2020 нче елның 1 нче гыйнварена Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге исеменнән 2019 нче елда бу муниципаль контрактларның шартлары нигезендә Товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактларның Саклаубаш авыл җирлеге исеменнән төзелгән, файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге бюджеты акчасы калдыклары 2020 нче елның 1 нче гыйнварына, 2020 нче елда Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге башкарма комитеты

тиешле карар кабул иткән очракта, әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

Статья 11
Татарстан Республикасы Финанс Министрлыгының казначылык органнары төзелгән киешүләр нигезендә Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

Статья 12
Әлеге карарны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” (PRAVO TATARSTAN. RU) һәм Татарстан Республикасы “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

Статья 13
Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан көченә керә.

Статья 14
Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Саклаубаш авыл җирлеге Советы рәисе: Л.М.Габидуллина